II нче кечкенәләр төркемендә эшчәнлеке конспекты

Фатыхова Алсу Файзелхак кызы әзерләде.

**Тема:**”Исәнме, су! ”
**Максат:** Суның сыйфаты белән таныштыру.
**Бурычлар:**
-Балаларның кызыксынучанлыкларын ,уйлау сәләтен һәм сөйләм телен үстерү
-суны куллана белү осталыгы тәрбияләү

-шәхси гигиена предметлары ,аларны куллана белү турында белемнәрен ныгыту

-сүзлек запасын арттыру (сыек,үтә күренмәле,агучан)

**Җиһазлар:** кыңгырау,таз белән су,стаканнар,буяу,трубкалар,лимонлы эфир мае,боз,суның табигатьтәге хәләте сүрәтләнгән рәсемнәр,зонтик,курчак “Алия”.

Эшчәнлек барышы:

Тәрбияче:Хәерле иртә,балалар!Әйдәгез ,исәнләшик әле:

Исәнме борын,

Исәнме авыз,

Исәнмесез күзләр,

Исәнмесез колаклар,

Исәнмесез ,балалар!

-Исәнмесез.

Балалар, без без сезнең белән бүген сәяхәткә китәбез!(Кыңгырау шалтырый).Бүгенге сәяхәттә без су турында сөйләшербез.Сез су турында нәрсәләр беләсез? Сунинди? (Балаларның җавабы)

Тәрбияче:Ә сезнең су турында күбрәк беләсегез киләме? Су нинди була ала икән? (Балаларның җавабы)

Тәрбияче:Балалар ,әйдәгез ачыклыйк әле , су нинди була икән.

Тәрбияче балалар белән өстәл янына килә.Балаларга стаканнар өләшә.

1 нче тәҗрибә: “Су сыек”

Тәрбияче:Балалар,әйдәгез стаканнарны су белән тутырабыз да стаканнардагы суны әкрен генә кире савытына бушатабыз.Без хәзер сезнең белән нишлибез?

Балалар: Суны кире савытына агызабыз.

Тәрбияче: Су нишли?

Балалар: Су ага.

Тәрбияче:Мин хәзер туп алдым.Туп нинди формада?

Балалар:Туп түгәрәк.

Тәрбияче: Мин тупны суга салам.Туп суда нишли?

Балалар: Туп суда йөзә.

Тәрбияче: Мин тупны хәзер кулда кысам,ул формасын югалттымы ?

Балалар: Юк.

Тәрбияче:Ә хәзер кулыгызда суны кысып карагыз әле ? Су нишли?

Балалар:Су кулдан ага.

Тәрбияче:Ә туп агамы?

Балалар:Юк.

Тәрбияче:Су нинди формада?

Балалар: Суның формасы юк.

Тәрбияче:Әйе, суның формасы юк.Без суны нинди савытка салсак ,су шул савытның формасын ала.Без сезнең белән суның  агучан ,сыек икәнен белдек.

2 нче тәҗрибә: “Су үтәкүренмәле”

Тәрбияче:Балалар, сез ничек уйлыйсыз ,су нинди төстә? (Балалар җавабы)

Әйдәгез , тәҗрибә үткәрәбез һәм суның нинди төстә булуын белербез.Тәрбияче бер-бер артлы ике стакан белән су күрсәтә.Берсендә чиста су,икенчесендә сөт белән буялган су.

Тәрбияче: Су нинди төстә?

Балалар:Су төссез?

Тәрбияче:Әйдәгез суны буейбыз,төсле ,матур су ясыйбыз.Балалар суны буей.

Тәрбияче:Хәзер тикшереп карыйк,буялган суда таякчыкны күрә алабызмы икән? Балалар суга таякчык тыгалар.

Тәрбияче: Балалар таякчык суда күренәме?

Балалар:Юк,таякчык суда күренми.

Тәрбияче таякчыкны чиста сулы стаканга тыга.

Тәрбияче:Чиста сулы стаканда таякчык күренәме?Бу стаканда су нинди төстә?

Балалар: Су үтә күренмәле?

Тәрбияче:Дөрес,суның төсе юк.Суның бу сыйфаты үтәкүренмәлелек дип атала.Димәк ,чиста су үтәкүренмәле.

3 нче тәҗрибә: “Суның исе һәм тәме юк”

Тәрбияче: Балалар, иснәп карагыз әле судан нинди ис килә?

Балаларның стаканындагы суга тәрбияче лимонлы эфир мае тамыза һәм балаларга гади су белән лимонлы эфир мае тамызылган суны чагыштырырга куша.Балалар чиста суның исе юклыгын ачыклыйлар.

Тәрбияче:Әйдәгез искә төшерик әле,суның тәме нинди?

Балалар:Суның тәме юк.

Тәрбияче:Афәрин ,балалар. Без сезнең белән су турында бик күп нәрсә белдек бүген.Ә хәзер карагыз әле, мин сезгә нәрсә әзерләдем.Тәрбияче алдан әзерләгән боз кисәге күрсәтә.Бу нәрсә?

Балалар:Бу боз.

Тәрбияче:Дөрес,бу боз.Ә сез ничек уйлыйсыз,боз нәрсәдән барлыкка килә?

Балалар:Боз судан барлыкка килә.

Тәрбияче:Боз нинди?

Балалар: Боз суык ,каты.

Тәрбияче:Әйе.Хәзер без бозның су икәнен исбатлыйбыз.Бозны тотып карагыз эле,бармакларыгыз нишләде?

Балалар:Бармаклар югешләнде.

Тәрбияче:Дөрес.Без бозны алып куеп торабыз һәм уйнап алабыз.Соңыннан бозның нишләгәнен карарбыз.

Дидактик уен:”Су кая качкан?

Тәрбияче балаларга суның табигатьтәге халәтләре төшерелгән рәсемнәр күрсәтә: елга,яңгыр ,кар,чык,болыт,күлләвек,шарлавык.Балалар белән бергәләп суның кая качканын табалар.

Тәрбияче:Балалар, бозны карыйк әле боз нишләгән?(боз суга әйләнгә)

Рефлекция:”Яңгыр тавышы”

Тәрбияче:Балалар,коверга җайлап утырабыз да күзләрне йомабыз.(Яңгыр тавышы тыңлыйлар) Сез нәрсә ишетәсез?(Яңгыр тавышын)

Физкульминутка:

Яңгыр кулга тамды (балалар уң куллары белән сул кулларына кагыла)

Чәчәкләргә яуды (куллары белән түгәрәк хәрәкәтләр ясыйлар)

Юлларны чылатты (кулларны алга сузалар)

Ой – ой –ой  яңгыр ява (башларын чайкыйлар)

Балалар өйгә чаба (балалар зонтик астына йогереп киләләр)

Тәрбияче:Бүген безгә кунакка  курчак “Алия”килгән.

-Исәнме ,Алия!

-Исәнмесез,балалар.

Тәрбияче:Ой ,исәнме шапшак кыз.

Кайда шулай булдың?

Кулларын кап-кара .

Беләкләреңне кара

-Урамда уйнадым һәм булдым.

Тәрбияче:Балалар әйтегеәз әле,мондый пычрак килеш еалырга ярыймы?

Балалар:Ярамый

Тәрбияче:Нигә  ярамый?

Балалар:Пычрак ул микроб.Аннан чирләргә мөмкин.

Тәрбияче:Алиягә нишләргә соң хәзер?

Балалар:Юынырга кирәк

Тәрбияче:Балалар,әйдәгез Алиягә юынырга булышыйк .Тәрбияче курчакны юуындыра:

Мә су,мә су

Бит,кулны ю.

Чиста су,чиста су

Ю,Ю,Ю.

-Рәхмәт ,балалар .Мин хәзер нинди чиста.Мин дә сезгә бүләк алып килдем.Урамга чыккач уйнарсыз.(Тәрбияче курчакның сумкасыннан сабын куыгы ала).Ә хәзер мина китәргә вакыт.Сау булыгыз,балалар!

Тәрбияче:Рәхмәт,Алия.Саубул.

Балалар ,сез бүген су турында нәрсәләр белдегез?

Балалар:су сыек,үтәкүренмәле,су иссез,тәме дә юк.

Тәрбияче:Афәрин!Булдырдыгыз.Хәзер сабын куыгы белән уйнарга урамга чыгабыз.